КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 4 декабрь г.Казань № 1037

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү турында» 2022 ел, 9 август, 775 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен

бәяләүне үткәрү турында» 2022 ел, 9 август, 775 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 26 июнь, 753 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибенең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гаризага, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы белән килештереп, вәкаләтле орган тарафыннан расланган документлар исемлеге теркәлә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән документлар оешма тарафыннан вәкаләтле органга яки вәкаләтле орган тарафыннан комиссиягә кәгазьдә яки, әлеге Тәртипнең таләпләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасын файдаланып тапшырыла.

Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән, дәүләт органнары, аларның ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны, әгәр әлеге документлар оешма тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылмаган булса, соратып ала.»;

әлеге карар белән расланган Балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерүче Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү тәртибенең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән гаризага, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы белән килештереп, вәкаләтле орган тарафыннан расланган документлар исемлеге теркәлә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән документлар оешма тарафыннан вәкаләтле органга яки вәкаләтле орган тарафыннан комиссиягә кәгазьдә яки, әлеге Тәртипнең таләпләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасын файдаланып тапшырыла.

Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән, дәүләт органнары, аларның ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны, әгәр әлеге документлар оешма тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылмаган булса, соратып ала.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү һәм әлеге комиссия тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибендә:

3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комиссия составы вәкаләтле орган акты белән раслана. Комиссия, рәисне кертеп, кимендә биш кешедән тора. Комиссия составына вәкаләтле орган хезмәткәрләре, башка кызыксынучы дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре керә. Шул ук вакытта вәкаләтле орган вәкилләренең саны комиссиянең гомуми составыннан кимендә өчтән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. Комиссиянең социаль инфраструктура объектын файдалану турында, оешманы үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү хакында бәяләмәсе, дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин